Балалар, ишетегез мине!

Менә 2002 нче ел җитте. Күрәсең, минем соңгы елымдыр. Күңел сизә. Ә мин үкенмим, озак гомер яшәргә туры килде. Бу хатны да киләчәк буынга, яшьләр сезгә, мөрәҗәгать итеп язам. Аны укып,үзегезгә сабак алырсыз дип ышанам.

Мин, Нуртдинова Рәбига Шәйсолтан кызы, 1915 елның 10 нчы июнендә туганмын. Әйе, узган гасыр башы. Миңа озын, озак гомер яшәргә һәм бик күпне күрергә насыйп булды. Гаиләбез ишле, әмма бай түгел. Урта хәлле гаиләләр рәтендә идек. Утарыбызда 1 ат, ике сыер, 10 баш сарык бар иде. Булган җиребезне үзебез эшкәртеп, әти-әниебезгә булышып яшәдек. Беркайчан эштән качканыбыз булмады. Заманында көне-төне эшләп чыгарга, 2 сәгать йоклаган килеш сыер саварга, аннан көтү көтәргә чыгарга да туры килгән көннәр аз булмады.

Без гаиләдә 5 бала үстек: мин – уртанчысы. Миннән кала, ике абыем һәм ике сеңлем үсте. Без тату үстек. Арабызда нәрсәдер өчен низаг чыкканын бер дә хәтерләмим. Шаккатырлык та юк. Ә нәрсә өчен талашыйк?! Бар булганы уртакка салында, “бергә тапкан кадерлерәк” ди торган иде мәрхүм атабыз.

Тормышыбызның авыр булуына карамастан, булганның кадерен белеп яшәдек. Ашаганда, өстәл астына төшкән бер валчык икмәге күрмәс идегез. Менә ни дәрәҗәдә зур иде икмәк кадере! Без бердәм һәм тату булып үстек. Зурлар кечеләргә, ә кечеләр кулларыннан килгәнчә безгә ярдәм итәргә тырышалар иде. Атабыз да, анабыз да һәр адым бердәм туганнарның бу авыр тормышта иң зур байлык булуын ассызыклап тордылар.

Шул ук вакытта әти-әниебез укуның ни дәрәҗәдә мөһим булуын да аңлата иделәр. Татар халкының искиткеч бай күңелле милләт булуын анабыз җырларыннан аңладым. Искиткеч моңлы, тәннең һәр күзәнәгенә үтеп керерлек иде алар. Үсә төшкәч, анабыз безне татар халык бәетләре, риваятьләре белән таныштырды. Аларны тыңлап, күз алдына борынгы кешеләр, аларның көнкүреш рәвеше, характерлары, буй-сыннары килеп баса иде. Шулар аша анабыз безне көчле, сабыр, түзем, акыллы, зирәк, бердәм булырга өйрәтергә тырышкан дип уйлыйм.

6-7 яшьләр тирәсендә атабыз мине Сабира абыстайга сабакка йөртә башлады. Аның белән гарәп язуын өйрәнү, гарәп графикасында язылган әлифбаны уку минем өчен шулкадәр кызык булды, өйгә кайткан саен яртышар сәгать анамның артыннан йөреп, аңа бүген дәрестә өйрәнгәннәрне сөйләп аптыратып бетерә идем. Әмма 1921 ел... Бик яхшы хәтерлим мин аны. Нәкъ менә шул ел минем ике сеңлемнең берсен алып китте... Ачлык, тиф һәм алардан да куркыныч булган күзләре ачлыктан томаланган, яшәү мәгънәсен югалткан кешеләр...

Шулай да Ходай ярдәме белән бу бәлане үткәреп җибәрдек. Бу елда туган авылыбызда югалтулар күп булды. Сеңлем мәрхүм булу сәбәпле, үзебезнең дә күңелләребез төшенке иде. Анамның айлар дәвамында төн җиткәч, мич артында елавын ишетергә туры килде. Әти дә кинәт картаеп китте. Иле белән зур үзгәрешләр, авырлыклар кичрдек бит...

Вакыт узуын сизеп бетереп булмады. Шул арада кияүгә чыгар чаклар да җиткән икән. Аңа мин бик шатланып һәм шул ук вакытта куркып каршы алдым. Туган йорттан китәсе килмәде, әмма сөйгәнем янына китәм бит дип тынычландырдым үземне. Шул ук вакытта алда нәрсә көтә мине, нинди галәгә эләгермен – берни билгесез. Әмма гаилә корылды, тормыш дәвам итә. Алны-артны карарга вакыт та җитми. Хуҗалык һәм гаилә белән арада өзелергә туры килә. Көненә 24 сәгать тә әз дияргә мөмкин иде.

1941 ел, җәй... Каһәр суккан 4 ел... Сугыш... Ничә миллион гаиләне ятим калдырган сугыш... Ул беркемне дә, бернәрсәне дә җәлләмәде. Җир йөзеннән күпме кеше, күпме авыл, шәһәр бергаепсезгә юкка чыгарылды. Совет солдатларының аяусыз, батыр холкы гына бу коточкыч сугышны 4 елда тәмамларга ярдәм итте. Ул да булмаса, нишләр идек? Язар идемме сезгә хәзер әлеге хатны?

Аннан соң тормыш яхшырак якка үзгәрде. Балалар үсте. Мин ялгызым булсам да, аларга төпле белем бирергә, белемле шәхесләр үстерергә тырыштым. Үзем белем ала алмагач, белем дөньясына ачкыч табарга мөмкинлек булмагач, 3 баламның һәрберсенең тиешле белем алып үсүләрен теләдем. Теләгемә ирештем дә: олы улым – инженер, урта кызым – югарыл категорияле табиб, ә кече улым – Рәсәй армиясенең генерал-майоры. Инде балалар үсеп җиткәч кенә, белемнең кеше тормышында ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуына чын мәгънәсендә төшендем.

Мөмкинчелек булу белән, тарихи китаплар, татар әдипләренең танылган әсәрләре белән таныша төштем. Искиткеч кызыклы икән!!! Тарихта татар халкының бөек һәм алдынгы булуына күпме мисаллар табарга мөмкин.

Дөресен әйтергә кирәк, балалар белән үзем дә белем алдым. Башта мәктәп программасын үзләштердек, аннары институтта да бергә белем алдык. Алар укыган хезмәтләрне бергәләшеп өйрәндек. Шул вакытта Тукайның искиткеч үз милләте өчен әрнеп язган шигырьләре, Мусаның тоткынлыкта иҗат иткән үлмәс әсәрләре һәм күп кенә башка талантлы язучы, шагыйрьләрнең иҗади җимешләре белән танышырга туры килде.

Тукай белән танышу үзе бер искитмәле вакыйга булып чыкты. Ни өчен дисезме? 27 яшенә дә җитмичә, тормыш гаделсезлеген күреп, шуңа чын күңелдән ачынган, милли ярсыну белән иҗат ителгән әсәрләрен уку үземнең ни дәрәҗәдә томана булуымны тагын бер кат ассызыклады. Ул бит инде шул

заман гади крестьян тормышының ни дәрәҗәдә гаделсез, хөкүмәтнең алдау, гади халыкны кыерсытуга нигезләнгән сәясәтен күреп курыкмыйча язган. Ә без аны белмәгәнбез, ишетмәгәнбез!!! Аның әсәрләрен укыгач, үзебезнең томаналыгыбызга үкендем, бу бер, икенчедән, күпме вакытның бушка, кул кушырып утырып үткәнен аңлап, күңел үзебез өчен тагын да әрнеде.

Бу әле Тукай гына (гына диюем өчен инде ачунласын). Аннан кала, үзебезнең тормыш, милләт, сәясәт проблемаларын яктырткан күпме әдипләребез бар. Арабызда искиткеч талантлар яши, иҗат итә. Минем кебекләр генә, тормыш йөген тартырга мәҗбүр булганнар, көне-төне бер кисәк ипи өчен эшләргә мәҗбүр булганнар, заманында надан калып, тормышның тагын әле хәл ителми калучы мәсьәләләрен белми йөргәнбез.

Татар әдипләренең, вакытында тыелган һәм яңадан кайтарылган әсәрләрен уку бик тә кызыклы һәм мавыктыргыч булды. Әйтик, Гаяз Исхакый иҗаты. Без аның әсәрләре белән 90 нчы еллардан соң таныштык. Моңа кадәр аның әсәрләрен уку мөмкин түгел иде, алар тыелган иде.

Үсмер вакытта миңа “Рабига, бар, укы, белем ал! Тормыштан артта калуың бар!” диюче булса иде шул...

Балакайларым!!! Миңа инде ни дә булса үзгәртергә соң. Әмма сез – безнең якты киләчәгебез. Бу сүзләрне ышанып әйтәм. Әйе, төпле ышаныч белән, чөнки укыганнан соң минем күп нәрсәләргә күзләрем ачылды. Татар милләтенең гомер-гомергә талантлы, бай мираслы, бай тарихлы, үтә югары мәдәниятле булуын аңладым. Әмма үзем аның киләчәге өчен берни эшли алмадым. Заманында моның өчен белемем җитмәде. Тормыш мәшәкатьләренә батарга мәҗбүр булдым. Тик хәзер заманы башка. Тормышыбыз уңайлы, җайлы. Без күз алдына китерә алмаганнар хәзер чынга ашты.